РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

28 октября 2022г. с. Тюлячи № 220

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 22 номерлы «16 яшькә житкән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 22 номерлы «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган 16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.6 пунктын өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәтне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Мөрәҗәгать итүченең ризалыгы (гарызнамәсе булу) белән муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда Республика порталы аша күрсәтелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү тәртибе Регламент белән билгеләнә.»;

б) 2.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда күрсәтелгән очракта, Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән алып 3 эш көне.»;

в) 2.5.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга

«Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда республика порталы ярдәмендә күрсәтелгән очракта:

мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт алуга ризалыгы (гарызнамәсе).»;

г) түбәндәге эчтәлекле 2.6.2.1 пункты белән тулыландырырга:

«2.6.2.1. Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда Республика порталы аша күрсәтелгән очракта, Регламентның 2.6.1 пунктында каралган,

Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасында булган һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә алынган белешмәләр кулланыла.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 2.7.1.1 пункты белән тулыландырырга:

«2.7.1.1. Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда Республика порталы аша күрсәтелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту каралмаган.»;

е) 2.10 пунктын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 52 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы һәм аларны күрсәткән өчен түләүнең иң чик күләмен билгеләүче оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» карары» ;

ж) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә, гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары бар, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да.»;

з) түбәндәге эчтәлекле 3.4.4.1 пункты белән тулыландырырга:

«3.4.4.1. Муниципаль хезмәт алдан ук (проактив) режимда Республика порталы аша күрсәтелгән очракта, ведомствоара гарызнамәләр җибәрү гамәлгә ашырылмый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле белешмәләр Регламентның 2.6.2.1 пунктында каралган тәртиптә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып алына.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин